ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

СОВЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422620 с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

2019елның 1 ноябендәге 22 номерлы

КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге составына керүче Державино торак пунктындагы гражданнар җыены карары.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Державино авыл җирлеге составына керүче Державино торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Державино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Державино авыл җирлеге территориясендә мөселман зиратына киртә кую;

- Державино авыл җирлеге территориясендә мөселман зиратына юл салу.

3. Әлеге карарны Державино авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче:_________________ И.И. Камалиева

Башлык - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы-

Державино авыл җирлеге  Советы  рәисе ____________   И.И. Камалиева